МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**19.09.2022** Казан шәһәре **№343**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кергән ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә боерам:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кергән ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен расларга.

2. Билгеләргә:

ришвәтчел юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге катнашында ришвәтчел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла;

ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларының һәм конфиденциаль характердагы мәгълүматларның сакланышы өчен җаваплы.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 19 сентябрендәге 343 номерлы боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кергән ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законны (алга таба – Федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнардан килгән, үз эченә Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – хезмәткәрләр) тарафыннан, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Министрлык эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы эшчеләр (алга таба – эшчеләр) тарафыннан кылынган ришвәтчелек һәм куркытып алу, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибе таләпләрен бозу фактлары, шулай ук хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган башка гамәлләр турында белешмәләрне алган мөрәҗәгатьләрне (алга таба –мөрәҗәгать) карау үзенчәлекләрен билгели.

Башка затларга карата шундый ук фактлар турында белешмәләр булган мөрәҗәгатьләр Федераль законның 8 статьясындагы 3 өлеше нигезендә компетенциясенә куелган мәсьәләләрне хәл итү кирә торган тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

Мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган хокукка каршы гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булганда, мөрәҗәгать аларның компетенциясе нигезендә хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

2. Министрлыкка килгән мөрәҗәгать теркәлә һәм Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

3. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хезмәткәргә карата хезмәт тикшерүе үткәрү башлана. Хезмәткәрдән кергән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар буенча язмача аңлатмалар алына.

4. Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча бәяләмә нигезендә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән ришвәтчелек чагылышы билгеләренең булуы турында фактлар расланган очракта, министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) күрсәтелгән бәяләмәне алган көннән алып өч эш көне эчендә материалларны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссиясендә карау турында карар кабул итә.

Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча законга каршы әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган кеше турында билгеле булган очракта, тиешле мәгълүмат әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакытта үз компетенцияләре нигезендә хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

5. Эшчегә карата тиешле фактлар расланган очракта, аның язмача аңлатмаларын анализлаудан чыгып, аңа Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында боерык чыгарыла.

6. Мөрәҗәгать җибәргән гражданга җавап әзерләү Министрлыкта коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан башкарыла.

Мөрәҗәгатьне карауда катнашучы затлар, гражданинга җавап җибәрү срогы чыкканчы кимендә 15 көн кала, мөрәҗәгать буенча язмача үз тәкъдимнәрен вазыйфаи затка җибәрәләр.

7. Мөрәҗәгатьтә җаваплы затка карата ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар турында белешмәләр булса, ул, үз кандидатурасын үзе кире кагып, мөрәҗәгатьне карауда катнашмый. Мондый мөрәҗәгатьне карау дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге, шулай ук юридик бүлек тарафыннан башкарыла.